СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

_____________№_____________

На № 4216 от 27.08.2021

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлегенең генераль планын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы беренче өлеше 20 пункты, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 30-32 статьялары, Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге генераль планы проекты буенча каршылыкларны җайга салу буенча килештерү комиссиясе утырышының 2020 елның 20 июлендәге беркетмәсе, район уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлегенең генераль планын расларга.
2. Сәмәкәй авыл җирлеге Советының 2014 елның 15 декабрендәге 30 номерлы, 2012 елның 7 ноябрендәге 24 номерлы карарлары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлегенең генераль планын барлык үзгәрешләре белән юкка чыгарырга.
3. Сәмәкәй авыл җирлеге Советының 2014 елның 15 декабрендәге 30 номерлы, 2012 елның 7 ноябрендәге 24 номерлы карарлары үз көчен югалткан дип санарга.
4. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
5. Әлеге карарны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырып чыгарырга.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль район
Башлыгы урынбасары

Р.И. Закиров